Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«14» ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында беренче сорау бунча.

2021 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыены каравына чыгарыла торган сорауга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәләнгеш авылы чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектларының тирә-юнен тәртипкә китерү, ремонтлау һәм төзекләндерү» сүзләрен «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәләнгеш авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау, карап тоту, кышын карап тоту;

- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектлары тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү» сүзләренә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Сәләнгеш авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау, карап тоту, кышын карап тоту;

- Сәләнгеш авылында су белән тәэмин итү объектлары тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.Н. Пинин

Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин